| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 02.08.2022

КАРАР № 822

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 23 маендагы 534 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 өлеше, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категорияләрдәге гражданнарга социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар бирү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 23 маендагы 534 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге хезмәткәре» сүзләреннән соң «яисә «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш сак идарәсе» дәүләт казна учреждениесе филиалы Нурлат районы буенча ведомстводан тыш сак бүлегенең хәрби хезмәткәре (хезмәткәре) яисә граждан персоналы заты» сүзләрен өстәргә;

2) 2 пунктта «2022 елга» сүзләрен «агымдагы финанс елына» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5нче пунктта:

- 1 пунктчада «Россия Эчке эшләр министрлыгының хезмәт таныклыгы» сүзләрен «эчке эшләр органнары хезмәткәре яисә милли гвардия гаскәрләренең хәрби хезмәткәре (хезмәткәре) яисә граждан персоналы хезмәт таныклыгы» сүзләренә алмаштырырга.

- 2 пунктчада «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «Нурлат районы буенча ведомстводан тыш сак бүлегенең - «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрен ведомстводан тыш саклау идарәсе» дәүләт казна учреждениесе филиалының хәрби хезмәткәрләре (хезмәткәрләре) һәм граждан персоналы затлары» сүзләрен өстәргә..

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мәдәниятне үстерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениеләре, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Атказанган спорт мастеры Галимҗан Салих улы Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениеләре, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Ледок» хоккей буенча спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе җитәкчеләренә 2022 елның 1 августыннан «Нурлат районы буенча Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрен ведомстводан тыш саклау бүлеге» граждан персоналы һәм хәрби хезмәткәрләр (хезмәткәрләр) өчен түбәндәге ташламалар билгеләү мөмкинлеген карарга.

- Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре Региональ тарих музеена бушлай бару;

- «Г.С. Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» МБУнең «Тулпар» спорт сарае базасына атнасына бер тапкыр  бушлай йөрү;

- «Ледок» хоккей буенча спорт мәктәбе» МАУнең «Ак Барс» спорт үзәге базасында чаңгыларны бушлай бирү (прокатка).

3. Әлеге карарның 1 пункты 2022 елның 1 августыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында (nurlat.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йокләргә..

Җитәкче Р.Р. Хәмзин